ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МЭСЭДЕ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ЖИТӘКЧЕСЕ
423753,Мәсәде авылы,
Нефтяников ур.,18нче йорт
Тел.3-44-49.
e-mail: masad.akt@yandex.ru

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
РУКОВОДИТЕЛЬ МАСАДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА
АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
423753,деревня Масады,
ул.Нефтяников,дом 18,
тел.3-44-49.
e-mail: masad.akt@yandex.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«27» гыйнвар 2026 ел №6

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы “Мәсәде авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге буенча җир куллану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча җәмәгать тыңлаулары үткәрү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1, 24 һәм 28 статьяларына, 2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында"гы 131-ФЗ номерлы Федераль законга һәм Актаныш муниципаль районының Мәсәде авыл җирлеге Уставына туры китереп, Актаныш муниципаль районы Мәсәде авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының "Мәсәде авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге буенча җир куллану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча җәмәгать тыңлауларын 2026 елның 3 нче февраленә билгеләргә.
2. Җәмәгать тыңлаулар үткәрү урыны итеп:
   - Бурсык авылында, Бурсык авылы, Куйбышев тыкрыгы, 4 нче йорт адресы буенча урнашкан Бурсык авыл мәдәният йорты бинасы, үткәрү вакыты 10:00;

   - Мәсәде авылында, Мәсәде авылы, Нефтяниклар урамы, 18нче йорт адресы буенча урнашкан Мәсәде авыл клубы бинасы, үткәрү вакыты 14:00;

3. Җәмәгать тыңлауларында каралачак мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр һәм фикерләр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Татарстан Республикасы, Актаныш районы, Мәсәде авылы, Нефтяниклар урамы, 18 нче йорт.
4. Бу карарны авыл җирлегенең махсус мәгълүмат такталарында, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында: http:/aktanysh.tatarstan.ru адресы буенча “Авыл җирлеге” бүлегендә бастырырга.
5. Бу карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Мәсәде авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Гатин И.Т.